**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге**
**Советы**

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы,
Х.Такташ урамы, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Кубянского сельского поселения**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян,
ул. Х.Такташа, 1/1
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2022 ел. № 6

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2022 елның 30 ноябренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күәм авылы Х.Такташ,Космодемьянская, Л.Толстой,Лермонтов,Коммуна, Тынычлык, Тельман, Ленин урамының 1-52 нче йортларында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2022 елның 30 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күәм авылы Ленин урамының 53-130 йортларында,Г.Тукай, М.Җәлил, Мәктәп, Комсомол, Р.Зорге урамнарында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- - гражданнар җыенынын беренче этабын үткәрү вакыты –30 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенынын икенче этабын үткәрү вакыты – 30 ноябрь 2022 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр
- халык җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Күәм авылы, Коммуна урамы, 12 нче йорт каршында;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Күәм авылы, Ленин урамы, 108 нче йорт каршында;

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены

карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1/1 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Күәм торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

- гражданнар җыены турында Күәм торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә;

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- бензин белән эшли торган туң ваткыч сатып алу;
- 7 КВтлы генератор сатып алу;
- ике данә бензопила сатып алу;
- Күәм авылы зиратлары территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күәм авылы, Х.Такташ урамы 1/1 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы: Гатауллин Р.Р.